**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица
Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани
урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 июня 2026 ел. № 201

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында Әтнә район башкарма комитетының «Әтнә муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» 05.05.2021 ел, №120 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 19.01.2026 № 7 карары нигезендә Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Әтнә муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләрен булдыру чараларын тәэмин итү турында» 05.05.2021 ел, № 120 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү хакындагы нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.4. пунктында:

беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Мобилизация чорында, сугыш хәле гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар булганда һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару буенча:»;

икенче абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасының кирәкле көчләрен һәм чараларын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының кирәкле көчләрен җиһазлау һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;»;

1.2. Нигезләмәнең 4.5. пунктында:

беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Мобилизация чорында, сугыш хәле гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган хәвеф-хәтәрләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкның тормышын беренче чиратта тәэмин итү буенча:»;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

унберенче абзацның беренче җөмләсен түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«сакланып калган торак фондын инвентаризацияләү һәм аның торышын бәяләү, зыян күргән халыкны урнаштыру өчен аннан файдалану мөмкинлеген билгеләү, тораксыз калган кешеләрне вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларына урнаштыру.»;

1.3. Нигезләмәнең 4.6. пунктында:

беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Мобилизация чорында, сугыш хәле гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә килеп чыккан янгыннарга каршы көрәш буенча:»;

өченче абзацта «сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. Нигезләмәнең 4.9. пунктында:

беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә::

«4.9. Мобилизация чорында, сугыш хәле гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә зыян күргән районнарда тәртипне торгызу һәм саклау буенча:»;

1.5. Нигезләмәнең 4.12. пунктында:

беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар булганда халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү буенча:»;

икенче абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«икътисад объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча комиссия төзү һәм аның эшен оештыру;»;

алтынчы абзацта «тыныч һәм сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов